| ГЛАВА СТАРОЧЕКАЛДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧЕКАЛДА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.10.2022 Иске Чекалда авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Чекалда авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Чекалда торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 11 ноябрендә 14 сәг. 00 мин. гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2023 елда үзара салым акчаларын кертүгә һәм куллануга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Чекалда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт узучы затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булганнардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллап, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану”:

1. Иске Чекалда авылында күмү урыннарын карап тоту буенча чаралар:

- зиратны коймалау өчен, контейнер мәйданчыгы өчен, зират территориясендә гомуми файдалану урынын төзекләндерү өчен материал сатып алу һәм хезмәт килешүе буенча эшләр өчен түләү

2. Иске Чекалда авылын төзекләндерү чаралары:

- урам утлары өчен лампалар, фонарьлар һәм чыгым материаллары сатып алу, агымдагы ремонт ясау, хезмәт килешүе буенча эшләр өчен түләү.

Иске Чекалда авылында юл эшчәнлеге чаралары:

- грейдлау, урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Иске Чекалда авылы, Чкалов урамы, 3нче йортта, авыл клубы бинасында гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы П.М. Королев